ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

# «ЕГЗӨК»

СЕНТЯБРЬ, 2015нче ел

№1(20)

## ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!






Беренче сентябрь... Көзнең беренче көне... Беренче кыңгырау... Беренче укытучы... Белем иленә беренче адымнар...

Чәчәкләр тотып, матур итеп киенеп, ярым куркып, ярым кызыксынып һәм күпмедер дәрәҗәдә горурланып, мәктәпкә таба атлаган адымнар. Әлеге олы юлга кереп киту нәкъ менә шушы беренче адымнардан тора. Мондый адымнар әле безнең тормышта еш кабатланыр. Көн арты көн үтелер, китап арты китап укылыр, белем өстенә белем, тәҗрибә өстенә тәҗрибә өстәлер.

Әлеге көн һәр кешенең дә диярлек күңелендә сакланадыр. Мәктәптә уку еллары безнең тормышыбызда зур урын алып тора. Мәктәпне тәмамлаган чакта без инде тагын да зуррак юлга адым атлар кешеләр булып тәрбияләнеп чыгабыз. Әлеге юллар безне дөньяның төрле төбәкләренә алып китәргә сәләтле.

Әмма, кайда гына китсәк тә, без үзебезнең кем булып чыгуыбызга әти-әниләребез белән беррәттән мәктәпкә һәм анда белем биргән беренче укытучыларыбызга рәхмәтле булачакбыз.

Тагын шуны әйтергә кирәк: адымнар бары тик үз көченә ышанганда һәм белемнәрең ышанычлы булганда гына ныклы булалар. Кайда гына барсагыз да һәрвакыт белемнәрегез күп һәм ышанычлы, атлар адымнарыгыз ныклы булсын! Аеруча - белем ачкычын алырга дип мәктәпкә барган беренче адымнар!

Укучыларны, аларның әти-әниләрен һәм укытучыларын чын күңелдән бүгенге Белем бәйрәме белән тәбрик итәбез! Укуыгызда уңышлар, ныклы сәламәтлек, яңа белемнәр алган вакытта күзләрегездә очкыннар ялтырап торуын телибез! Өстә әйтелгән теләкләргә өстәп тагын шуны әйтәсебез килә. Иң ныклы, иң яхшы, иң истә кала торган белемнәр - үз туган телеңдә алынган белемнәр! Без моны бик яхшы беләбез, күп еллык тәҗрибәбез моңа дәлил булып тора!

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Белем бәйрәме | 2 |
| «Мин—талантлы» сыйныф сәгатьәре | 3 |
| Якыннан танышыйк | 4 |
| Корбан гаете | 4 |
| Бакчабыз да бакчабыз | 4 |
| Варислар туган көне | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |

# «Мин— талантлы»
# Мәктәптә беренче сыйныф сәгатьләре

1 сентябрь көнне мәктәбебезнең барлык сыйныфларында “Мин талантлы” дигән темага сыйныф сәгатләре үтте. 7 нче сыйныф укучылары ветеран укытучыбыз, озак еллар буе балаларга татар_теле һәм _әдәбият фәннәрен укыткан Салахова Рәзинә Гарифовна белән очраштылар. 9 сыйныф укучылары күп укытучыларга остаз булган ветеран укытучы Абдуллина Роза Вәлиәхмәтовна белән әңгәмә алып барса, сигезенчеләр озак еллар буена мәктәбебезнең директоры булып эшләгән Кәримов Сәлим абый белән аралаштылар. Әңгәмә барышында талантлы кеше нинди була, уңышка ирешүнең нинди юллары бар? дигән сорауларга бергәләп җавап таптылар. Очрашуда мөхтәрәм кунаклар укучыларга укуда зур уңышлар, максатларына ирешүдә зур тырышлык теләделәр. Укучыларга беренче сыйныф сәгате бик ошаганлыгы ачыкланды.

## Фоторепортаж



























# Якыннан танышыйк



**Укучыларның сорауларына укытучы Галлямова Гөлүсә Фоатовна җавап бирә.**

*- Ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз ?*

-Кечкенәдән укытучы булып уйнадым, шул балаларны ярату хисе , алар белән эшләү теләге булу, укытучы булырга эндәде .

*- Сез кайсы дәресне ныграк яраттыгыз?*

- Физкультура, тарих, математика фәннәрен аеруча яраттым.

*-Үзегезнең яраткан укытучыларыгызны хәтерлисезме?*

-Әлбәттә, барысын да хәтерлим.

*-Начар билге алсагыз кайгыра идегезме?*

-Начар билге бик алмадым. Бер тапкыр шигырь ятламау сәбәпле «3»ле алган идем. Шул көнне мәктәбебезгә кунаклар килгән иде, мин өйгә эш бирмәгәннәр диеп мәктәпкә килдем. Ә өй эшенә шигырь ятларга булган икән. Мәктәпкә килгән кунаклар алдында шул шигырьне начар сөйләгәнгә «3»ле куйган иделәр.

*- Укытучы эшендә иң ошаганы нәрсә?*

-Кеше, балалар арасында, коллективта булган вакытта бөтен булган борчуларың, мәшәкатьләрең онытыла .

*-Сезнең яраткан китабыгыз?*

- Габдрахман Әбсәләмовның «Ак чәчәкләр», Вакыйф Нуруллинның «Әгәр син булмасаң» дигән әсәрләре.


*- Сезгә кайсы төс ошый?*

- Бөтен булган ачык төсләр.

*- Сез матур биисез, бу сезнең бердәнбер хоббиегызмы?*

- Дөресен әйткәндә, биюдән битәр, пешерергә һәм чигәргә яратам.

## Корбан бәйрәме



Ураза бәйрәменнән соң 70 көн узгач билгеләп үтелүче Корбан гаете хаж гамәле тәмамлану вакытына туры килә. Хаж сәфәрендә булмаса да, хәленнән килгән барча мөселман бу көнне Аллаһы ризалыгы өчен корбан чалырга һәм якыннарын, туган-тумачаларын, мохтаҗларны куандырырлык гамәлләр кылырга тиеш.

Быел 24 сентябрьдә барлык мөселманнар Корбан бәйрәмен билгеләп үтте. Бәйрәм өч көн булды.

*Аяз Әһлиуллин*




**Таян Аллага!**

*Габдулла Тукай*

Әй бәһале, әй кадерле,
эй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның,
һәрдәм таян син Аллага!
Йа Ходай, күрсәт, диген
ошбу җиһанда якты юл;
Ул рәхимле; әткәең-әнкәңнән дә
күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең,
һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз
сүзләр әйтеп күрмәгән.
Пакь җаның һәм пакь тәнең –
барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың,
йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән
тезләнә дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры
Юл бар гаршенә!
Әй бәһале, әй кадерле,
эй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның,
һәрдәм таян син Аллага!

***Актуаль мәсьәлә***

## Бакчабыз да бакчабыз

Менә алтын көз житте. Бакчада төрле- төрле яшелчәләр өлгерде: кишере, чөгендере, бәрәңгесе һәм башка җиләк-җимеше дисеңме – барысы да. Иренмичә вакытында җыеп ал гына. Ә бәрәңгеләрне, чөгендерне, кишерне алганнан соң, кышкыга дип, без базга салабыз. Аннары бакчаны яфраклардан чистартып, казып, ашламалар сибеп калдырабыз. Икенче елга да без анда яшелчә утыртачакбыз.

«Нәрсә өчен кирәк соң ул яшелчәләр?» дигән сорау туа миндә. Әлбәттә, безнең организм өчен файдалы витаминнар алар. Суган һәм шалкан салкын тиюдән саклый. Чөгендер кан өчен әйбәт. Менә шундый файдалы яшелчәләрне үзебез өчен карап, кадерләп үстерергә кирәк тә инде.

Чыннан да, менә нинди ел фасылы ул көз. Бөтен муллыгы, матурлыгы белән үзенә җәлеп итә. Табигатьне сары төскә күмә, агачлардан яфраклар коела. Юкка гына көзне алтын, димиләр. Көз көне көннәр кыскара, төннәр озыная. Салкын җил исә, көннәр тиз караңгылана. Көз җиткәнен сиздереп, яңгырлар ява башлый. Кошлар, төркем-төркем булып, моңсу гына саубуллашып, җылы якларга очып китәләр.

Ә шулай да көз бик матур, күңелле, мул табынлы вакыт ул.

***Абдрахманова Рәзилә***



Кемгә ничектер, минем үземә көз көне бакчада эшләү бик ошый. Ни өчен дигәндә, көзге муллыкны җыеп алу - нинди зур куаныч. Кишер түтәлен казып, рәтләргә салабыз да, сабакларын кисеп, чиләкләргә тутырабыз. Кайберәүләр аларны ашханә подволына кертә. Кәбестә күчәннәрен зурлар урнаштыра. Бергәләшеп җир кишәрлеген чүпләрдән арындырабыз.

Мәктәп бакчасында үскән яшелчәләрдән пешкән ашны ашау, салатлар белән сыйлану укучыларга бик ошый. ”Хезмәте барның ашы да бар”, - дип, борынгылар бик дөрес әйткәннәр.

***Таһирова Гайшә***

***Чеметеп җыйсаң, учлап ашарсың!***





# *Көлке хикмәте*

*Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.*

*Мәзәкләр, гадәттә, мәҗлесләрдә, күмәк ял вакытларында җыелган кешеләрне бер көлдереп алу, аларның күңелен ачу максатында сөйләнәләр. Мәзәк – күңел ачкычы" дигән гыйбарә дә жанрның нәкъ шундый вазифасына ишарә итә.*

****

Вәли мәктәптән өенә кайтып кергәч:
- Житте! Бүтән бу мәктәбегезгә ике аягымның берсен дә атламыйм!
- Нишләп?
- Укый белмим, яза белмим, ә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмиләр.



****

- Айнур, минем компьютерым эшләми.
- Анда бер зур төймә бар, аңа басып карадыңмы?
- Әйе, барыбер эшләми.
- Розеткага тыкканмы?
- Белмим, хәзер шырпы кабызам да карыйм.
- Ә шырпы нигә?
- Бездә утны сүндерделәр...

****

Интернетта ике вирус очрашкан ди:
- Кая бардың?
- Әй, татар сайтларын агуларга барган идем лә...
- Нәрсә, барып чыкмадымыни?
- Әй, аларны Латиница дигән бер бик зәһәр вирус агулап бетергән икән инде...



****

ВУЗда экзамен бара. Профессор:
- Сезгә бер авыр сорау биримме, әллә ике җиңелнеме?
- Бер авырны.
- Алайса менә мондый сорау, җавап бир: Җир шарында мамонтлар беренче мәртәбә кайда табылган?
- Казанның Бауман урамында.
- Нигә анда?
- Ә монысы инде икенче сорау!

****

Әтисе улына:
- Улым, син үсеп җиттең инде, кем булырга уйлыйсың?
- Әти, мин Кыш бабай булырмын ахры!
- Нишләп? !
- Нишләп дип, чөнки ул Яңа елга кадәр бер атна һәм Яңа елдан соң бер атна гына эшли.

****

Автомәктәптә имтихан бара:
- Двигатель ничек эшли?
- Үз сүзләрем белән мөмкинме?
- Әлбәттә!
- Вжжжж! Вжжжж! Вжжжж!



****

Печән чапканда ике дус сөйләшә. Берсе икенчесеннән сорый:
-Син кемгә чабасың? - ди.
- Картайган көнемдә кешегә чабып йөрмәм инде, үземә чабам, - ди тегесе.
- Ә мин сыерга чабам, - ди дусты, серле генә елмаеп.

Бүген пионерлар оешмасы хәрәкәтенең дәвамы булып Татарстан варислары берлеге тора. Гәрчә куәтле пионер оешмасын  алыштыра алмаса да, кызыл галстук бәйләмәсә дә, республика флагы кебек өч төсле галстуклы укучылар: *"Без – данлы илнең яңа гражданнары! Безгә бабаларыбыз васыять итеп калдырган!"* – диләр.

Татарстан варислар берлеге яшь буын мәнфәгатьләрен чагылдыру, балаларга һәм яшүсмерләргә җәмгыятьтә үз урыннарын табу, төрле яклы үсешкә ирешергә ярдәм итү – аларда, яшь гражданнар буларак, җаваплылык хисе тәрбияләү бурычы куя. Бурычларны тормышка ашыру өчен, түбәндәге юнәлешләрдә эш алып барыла:

- хезмәт – файдалы эшләр башкару һәм укуда бер-береңә ярдәмләшү ул;

- тынычлык – әйләнә-тирә мохит турында кайгырту, туган якны өйрәнү, теләктәшлек ярминкәләре, тынычлык турында җыр фестивальләре үткәрү;

- кайгыртучанлык – шәфкатьлелек, өлкәннәргә һәм кечеләргә булышу, ялгызлар һәм авырулар турында кайгырту;

- ятышлылык – күңелле спорт стартлары, зирәкләр һәм тапкырлар клублары, концертлар оештыру, файдалы һәм кызыклы итеп ял итә белү;

- һөнәрләр – варислар сборларында сәяхәтләр вакытында һәм көндәлек тормышка кирәкле һөнәрләрне үзләштерү.

Оешмада башкарыла торган эшләр местәкыйльлеккә, ирекле аралашуга, үзеңә ошаган эшне сайлап ала белергә, сәләтеңне үстерергә өйрәтә.

15 сентябрь көнне мәктәбебездә Татарстан варислары берлегенең туган көнен билгеләп үттек. Быел аңа 25 ел тулды. Станцияләр буенча уен-сәяхәттә 5,6,7 сыйныф укучылары бик теләп катнаштылар. Барлыгы җиде станция урнашкан иде. Ул— “Ашыгыч ярдәм” , “Уен” , “Кунакчыл”, “Дару үләннәре”, “Табышмаклар” , “Спорт”, “Җыр” станцияләре. Һәрбер станциянең үз алып баручысы беркетелде. Барлыгы өч отряд катнашты. Һәрбер отряд үз исеме, капитаны, девизы һәм җыры белән таныштырды. Барлык отряд та станциядәге җәзаларны үтәп, финишка юл тотты. Уенда актив катнашучы отрядлар грамота белән бүләкләнде. Бәйрәм һәркемнең күңеленә хуш килде.

## Бәйрәмнән фоторепортаж















## Мастер-класс «Ёжики» своими руками

**Необходимый материал:**

пластиковая бутылка, две крышки из-под пластиковых бутылок, сосновые шишки, клей « Момент» или монтажная пена, пла-




1. На пластиковую бутылку с помощью клея или монтажной пены приклеиваем шишки (иголки ежа). Каждую шишку клеим отдельно, крепко прижимая к бутылке.
2. Затем крышку бутылки (нос ежа) обклеиваем пластилином черного цвета.
3. На 2 крышки белого цвета клеим кусочки пластилина черного цвета, получились глазки.
4. Приклеиваем их к бутылки с помощью клея (пены).
5. Затем на «иголки» положить ягоды, грибы, вылепленные из пластилина.
6. Чтобы ёжику было не скучно, сделаем ежонка. Нам понадобится пластилин, семечки.
7. Из пластилина лепим маленького ежонка, иголки делаем из семечек, глазки и носик из черного пластилина.
8. Наши ёжики готовы.

## Сентябрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Абдрахманов Рифат, Вәлиуллина Әнисә, Хисматова Зәринә, Никулин Тимур, Закирова Гөлинә, Ибраһимов Зөлфәт, Кәбирова Дилбәр, Хисматов Рәсим, Хайбуллина Алсу, Замалеев Алмаз, Хәйруллин Булат, Гафурова Илүзә, Зиятдинов Фанил, Вәгыйзова Ләйсән, Әхмәтшина Дилия, Мазгутов Илназ, Сәгыйрова Әнисә!

Сезне барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , исәнлек телибез.

Озын булсын гомерегез,<br>
Тыныч булсын күңелегез.<br>
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,<br>
Зур шатлыклар белән таң атсын.



**Бу сан өчен мәктәпнең “Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Абдрахманова Рәзилә

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат<br>
Юнусова Виктория<br>
Таһирова Гайшә<br>
Садртдинова Рузилә